**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Сәвәләй авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**06.12.2022 ел**

**№ 84**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 24 маендагы 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы, Сәвәләй авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сәвәләй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Сәвәләй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 31 маендагы 68а номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Сәвәләй авыл җирлеге Советы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтының “Авыл җирлекләре” бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **И.А. Галимов**